Татарстан Республикасы **ЗАКОНЫ**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2007 елның 6 декабрендә
кабул ителде

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Архив фонды һәм архивлар турында» 1996 елның 13 июнендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына (алга таба — җирле үзидарә органнары) архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирә.

1 статья. **Архив эше өлкәсендә җирле үзидарә органнарына бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган һәм муниципаль берәмлекләр территориясендә булган архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм куллану буенча аерым дәүләт вәкаләтләре (алга таба — дәүләт вәкаләтләре) бирелә.

2 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекләрнең исемнәре**

Татарстан Республикасында түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә:

Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль

EV_1_08.indb 3 13.05.2008 12:20:13

районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

3 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган срок**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре чикләнмәгән срокка бирелә.

4 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бирелә торган финанс һәм матди чаралар**

1. Бирелгән дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

3. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләү, әлеге Законга кушымтада каралганча, Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләү методикасы нигезендә башкарыла.

4. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга бирелә торган матди чаралар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Җирле үзидарә органнарының әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен алынган финанс чараларын башка максатларга файдалануы тыела.

5 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) үз матди ресурсларын һәм финанс чараларын муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә файдаланырга;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан кирәкле консультация һәм методик ярдәм алырга;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча әлеге Закон нигезләмәләре нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән муниципаль хокукый актлар чыгарырга;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны бетерү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының язма күрсәтмәләренә Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә бурычлы:

EV_1_08.indb 4 13.05.2008 12:20:13

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы җирле үзидарә органнарын һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын билгеләргә;

2) архив эше турындагы законнарны, шулай ук дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үз компетенцияләре чикләрендә кабул ителгән норматив хокукый актларын үтәргә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган һәм муниципаль берәмлекләр территориясендә булган архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм куллану өчен кирәкле шартлар тәэмин итәргә;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субвенцияләрдән максатчан файдаланырга;

5) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисапларны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендә махсус вәкаләтле органына, Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субвенцияләрдән файдалану турындагы хисапларны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасында финанс, бюджет, салым һәм валюта сәясәте өлкәсендә махсус вәкаләтле органына бирергә;

6) бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендә махсус вәкаләтле органнары тарафыннан тикшереп тору өчен кирәкле шартлар тәэмин итәргә;

7) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торганда ачыкланган хокук бозуларны бетерергә;

8) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру туктатылган очракта, файдаланылмаган финанс чараларын, шулай ук матди чараларны кире кайтарырга.

6 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген үз компетенцияләре чикләрендә җайга салырга;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эше тәжрибәсен өйрәнергә, гомумиләштерергә, таратырга;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары яисә аларның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләр бирергә;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларына бәйле рәвештә кирәкле мәгълүматны һәм документларны билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарыннан соратып алырга.

2. Дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә бурычлы:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс һәм матди чараларны җирле үзидарә органнарына бирүне тәэмин итәргә;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарына аңлатмалар бирергә, консультация һәм методик ярдәм күрсәтергә;

3) җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларына бәйле рәвештә кирәкле материалларны һәм документларны аларның сораулары буенча бирергә;

4) дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнарының гамәлгә ашыруларын, шушы максатларга бирелгән финанс һәм матди чаралардан файдалануларын тикшереп торырга.

7 статья. **Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырулары турында хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырулары һәм финанс чараларын тотулары турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Рес-

EV_1_08.indb 5 13.05.2008 12:20:13

публикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән формалар буенча һәм вакытларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең махсус вәкаләтле органнарына хисаплар бирә.

8 статья. **Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торуны түбәндәгеләр башкара:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы — дәүләт вәкаләтләрен үтәүне тикшерүләр үткәрү, дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документларны һәм мәгълүматны сораты алу юлы белән;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасында финанс, бюджет, салым һәм валюта сәясәте өлкәсендә махсус вәкаләтле органы — дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән чараларны җирле үзидарә органнары тарафыннан тотуга комплексы тикшерүләр үткәрү һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерү һәм аларны булдырмау буенча тиешле чаралар күрү юлы белән;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә махсус вәкаләтле органы — дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган мөлкәттән һәм бүтән матди чаралардан тиешенчә файдалану һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерү, аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү өлешендә;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә махсус вәкаләтле органы — дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза һәм анализ үткәрү юлы белән.

9 статья. **Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату Татарстан Республикасы законы белән түбәндәге очракларда башкарыла:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен җирле үзидарә органнарының үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве;

2) әлеге Законны бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрне җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының үтәмәве;

3) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен үтәүләре мөмкин булмаслык итеп федераль законнарны яисә Татарстан Республикасы законнарын үзгәртү.

2. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелеп файдаланылмый калган финанс чараларын һәм матди чараларны кире кайтаруга китерә.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланганнан соң ун көн эчендә аларны бетерү турында җирле үзидарә органнарына күрсәтмә җибәрә.

4. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә җирле үзидарә органына кергән көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча һичшиксез каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендәге махсус вәкаләтле органына язма рәвештә кичекмәстән хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына җирле үзидарә органнары та-

EV_1_08.indb 6 13.05.2008 12:20:13

рафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында тәкъдим һәм Татарстан Республикасының тиешле закон проектын кертә.

10 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон нигезләмәләре, әгәр чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирү каралган булса, ел саен күрсәтелгән закон белән гамәлгә кертеләләр.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң өч ай эчендә әлеге Законга туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М. Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2007 елның 24 декабре
№ 63-ТРЗ

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта

Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләү методикасы

1. Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләү методикасы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән.

2. Дәүләт милкенә кертелә торган архив документларын саклауга, туплауга, исәпкә алуга һәм алардан файдалануга муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субвенция күләме түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$$S_i = Р \times П_i \times К,$$

монда:

S_i — муниципаль берәмлек өчен дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр күләме;

Р — саклау берәмлеген тотуның уртача хакына карата дәүләт вәкаләтләрен үтәүгә чыгымнарны исәпләү нормативы;

$П_i$ — агымдагы ел башлангандагы торышы буенча Татарстан Республикасы территориясендәге һәм муниципаль архивта саклана торган берәмлекләренең саны;

К — планлаштырыла торган финанс елына бюджет чыгымнары индексация коэффициенты.

EV_1_08.indb 7 13.05.2008 12:20:14